РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘРСОВЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail:Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2017 елның 15 декабре № 38

**Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегенең (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш), кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларын яклау инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга озак сроклы нигездә биләүгә һәм (яисә) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәте исемлеген раслау турында**

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе субъектларының дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге, кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендалый торган күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы уставына нигезләнеп, Түбән Кама шәһәр Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Кушымта нигезендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзүче оешмаларга биләүгә һәм (яисә) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге муниципаль мөлкәте исемлеген расларга.
2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама шәһәр Советының бюджет сәясәте һәм икътисадый үсеш буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры А. Р. Метшин

Түбән Кама шәһәр Советының
2017 елның 15 декабреннән
38 нче номерлы карарына
**кушымта**

| № п/п | Адрес | Исәпкә алу объекты исеме | Объектның үзенчәлеге, мәйданы, кв. м. |
|---|---|---|---|
| 1 | Татарстан Республикасы, Түбән Кама шәһәре Корабельная ур., 7 йорт, 1002 бүлмә | Торак булмаган бина № 1002 КN16:53:0405:1460 | 64,7 кв.м мәйданлы торак йорт подвалында торак булмаган бүлмә |
| 2 | Татарстан Республикасы, Түбән Кама шәһәре, Корабельная ур., 25 йорт, 7 бүлмә | Торак булмаган бина КN16:53:0402:2619 | 312,9 кв.м мәйданлы торак йортның 1 катындагы торак булмаган бүлмә. |

Түбән Кама шәһәре
Мэры урынбасары Э.Р.Долотказина